МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.02.2024 Казан ш. 48

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәсхи кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Вазыйфа бурычларын үтәгәндә Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәсхи кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга (кушымтада бирелә).

2. Министрлыкның (алга таба – Министрлык) дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләренең, шулай ук хезмәт контрактлары төзелгәндә – гражданнарны әлеге боерык белән таныштырып чыгуны;

әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшыруны;

әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталында Министрлык сайтындагы «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштыруны.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфа бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында» 2016 елның 22 мартындагы 77 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
«15» 02.2024 ел, № 48
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәрләре) тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү процедурасын билгели.

2. Хәбәр граждан хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә аңа бу турыда билгеле булуга вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында белдерү рәвешендә язмача формада төзелә һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министрына (алга таба – министр) җибәрелә.

3. Министр хәбәр килгән көннән алып өч эш көне эчендә аны коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) беренчел карау өчен җибәрә.

4. Гаризаларны теркәү өчен җаваплы зат вазыйфаи тарафыннан бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында гаризаларны исәпкә алу журналын алып барыла.

5. Хәбәрне алдан карау барышында җаваплы зат хәбәр җибәргән граждан хезмәткәреннән анда әйтелгән шартлар буенча аңлатмалар алырга, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга сораулар җибәрергә, шулай ук «Посейдон» коррупциясенә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланырга хокуклы, шул исәптән сорауларны юнәлтү өчен дә.

6. Хәбәрне алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Хәбәр, бәяләмә һәм алдан карау барышында алынган башка материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәр алынган көннән башлап җиде эш көне эчендә аның тарафыннан Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

7. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән сораулар юлланган очракта, хәбәр, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәр алынган көннән башлап 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин иң күбе 30 көнгә кадәр генә.

8. Комиссия Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмә нигезендә хәбәрне, бәяләмәне һәм башка материалларны карый.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министрына

________________________________

кемнән________________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)
________________________________
били торган вазыйфа)

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булган шартлар: ________________
________________________________________________________________________.

Минем шәхси кызыксынучанлыгым аларны үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясарга мөмкин вазыйфаи бурычлар: ____________________________________________
________________________________________________________________________.

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу һәм җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________
________________________________________________________________________.

Әлеге хәбәрне караганда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

| ___________ | _________________ | _________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |